ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

с. Верхний Услон

02.08.2021 №76

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турындагы карары проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан районында яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу хокукларын тормышка ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турында Нигезләмәгә таянып, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты мөрәҗәгатен карап тикшергәч,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының кадастр номерлары 16:15:110107:29, 16:15:110107:28, 16:15:110107:27, гомуми мәйданы 239,86 кв.м., 228,2 кв.м., 269,93 кв.м. булган, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Макыл авыл җирлеге, Рус Макыл авылы, Үзәк урам, 55 йорт, 1, 2, 3 фатир адресы буенча урнашкан җир кишәрлекләренә карата, «Индивидуаль торак төзелеше» Ж-1 территориаль зонасы чигендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм «аз катлы күпфатирлы йортлар» капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карары проекты буенча, иҗтимагый фикер алышуларны билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карап тикшерү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп билгеләргә (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы).

2.2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карап тикшерү буенча җәмәгать фикер алышуларын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә, 2021нче елның 3нче августыннан - 2021нче елның 22нче августына кадәр чорында үткәрергә.

2.3. Проектның экспозициясен үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасы, 2021нче елның 3нче августыннан - 2021нче елның 22нче августына кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты. Тәкъдимнәр, искәрмәләр 2021нче елның 3нче августыннан 2021нче елның 22нче августына кадәр сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр язмача һәм (яки) Zakiulla.Mingazov@tatar.ru электрон почта аша кабул ителә

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетына, җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган, әлеге рөхсәтләр сорала торган җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокукына ия булучыларга җиткерү өчен, проект буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын үткәрү турында хәбәр җибәрергә.

4. Мөрәҗәгать итүчегә (Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетына) җәмәгать фикер алышуларын оештыруны техник яктан тәэмин итәргә, шул исәптән экспозицияне үткәргәндә һәм әлеге рөхсәт сорала торган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокукына ия булучыларга җиткерүне тәэмин итәргә.

5. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

5.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне тәэмин итәргә.

5.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» өстәмә битендә проектлар буенча иҗтимагый фикер алышуларның башлануы турында хәбәр урнаштырырга.

5.3. 2021нче елның 3нче августыннан да соңга калмыйча Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» өстәмә битендә урнаштырырга:

- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының кадастр номерлары 16:15:110107:29, 16:15:110107:28, 16:15:110107:27, гомуми мәйданы 239,86 кв.м., 228,2 кв.м., 269,93 кв.м. булган, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Макыл авыл җирлеге, Рус Макыл авылы, Үзәк урам, 55 йорт, 1, 2, 3 фатир адресы буенча урнашкан җир кишәрлекләренә карата, «Индивидуаль торак төзелеше» Ж-1 территориаль зонасы чигендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм «аз катлы күпфатирлы йортлар» капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карары проекты.

5.4. Әлеге карарның 5.3. п. күрсәтелгән проектлар буенча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасында 2021нче елның 3нче августыннан 2021нче елның 22нче августына кадәр эш көннәрендә

8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында экспозицияләр оештырырга.

5.5. Иҗтимагый фикер алышулар тәмамлангач, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиятдинов